Татарстан Республикасы Арча районы

«Носы төп гомуми белем бирү мәктәбе”

муниципаль бюджет белем бирү учреждениясе

Тема: "Шушы яктан, шушы туфрактан без"
туган якны өйрәнү дәресләрендә региональ компонент аша тәрбия бирү.


Эшне башкарды: Татарстан Республикасы

Арча муниципаль районы

“Носы төп гомуми белем мәктәбе”

муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе

I квалификацион категорияле география

укытучысы Григорьева Лена Ильяс кызы


2020

Аңлатма язуы

География – укучылар тарафыннан яратып өйрәнелә торган фәннәрнең берсе. Дәресләрдә үтелгән темалардан тыш, аларны геология туфрак белеме, вулканология фәннәре, ерактагы илләр, андагы тормыш, табигатҗ һәм хайваннар дөньясы кызыксындыра.

Укучыларның кызыксыну ихтыяҗын канәгатьләндерергә омтылып, мин программа буенча өйрәнелергә тиешле темаларны тирәнәйтеп, өстәмәләр кертеп (махсус программа төзеп), алдынгы укучылар белән кластан тыш эшләр алып барам.

Һәр дәресне укучыларда табигатькә мәхәббәт, аңа сакчыл караш тәрбияләп, үзең яшәгән төбәк һәм республикаң турында күбрәк мәгълүмат туплау, география фәнен кызыксынып өйрәнүгә омтылыш тудыру максатыннан оештырам.

Милли төбәк компоненты халык һәм милләт үзенчәлеген, мәдәниятен һәм рухи дөньясын,телен һәм тарихын, табигый-географик мохитен , традицияләрен чагылдырган укыту материалын берләштерә. Укучы үзе яши торган төбәкнең табигатен, аның үзенчәлекләрен, халкын, традицияләрен, мәдәниятен, тарихын яхшы белергә тиеш.

Һәр төбәкнең үзенең күренекле шәхесләре була. Алар турында горурланып сөйләнелә, кылган гамәлләре хөрмәтләнә, яшь буынны да шулар үрнәгендә тәрбияләү максаты куела. Укучыларны туган якта туып үскән каләм әһелләренең иҗаты белән таныштырмый торып, географиядән алар үзләштерергә тиешле белемне тулысынча алалар дип әйтеп булмый.

Моның өчен төп игътибарны укучыларда туган ягыбызның күренекле кешеләренә, аның матур табигатенә ихтирам хисләре тәрбияләүгә, Татарстанның, Арча төбәгенең гүзәл җир булуын төшендерергә юнәлтәм. Туган җиребезнең яңадан – яңа серләре ачылып тора.
Проект методы эшчәнлегенең эпиграфы итеп кытай халкы мәкален кулланыр идем:
“Сөйлә миңа – мин онытырмын, күрсәт – истә калдырырмын, кызыксындыр - өйрәнермен”.

**Тема актуальлелеге:** федераль дәүләт белем бирү стандартларына (ФДБС) күчү шартларында укытучы эшчәнлегенең нәтиҗәле юнәлешләреннән берсе булып проектлар методы санала.

**Эшемнең төп максаты:** укучыларның шәхси үсешенә, уңышлы аралашуларына ирешү, аларны һәртөрле эшчәнлеккә иҗади якын килергә өйрәтү.

**Проектның бурычлары:**

-укучыларда интеллектуаль һәм гомумхезмәт белемнәрен булдыру, аларның хезмәт нәтиҗәләрен күз алдына китереп эшләрлек күнегүләр белән тәэмин итү;

-иҗади фикерләү, мөстәкыйльлек һәм башлап эш итү сәләтен үстерү;

-компьютер белән эшләү, мәгълүматны эзләү һәм эшкәртү күнекмәләрен булдыру;
-тыңлый белергә һәм башкаларның фикерен ихтирам итәргә өйрәтү; димәк, команда белән эш итәргә өйрәтү;
-уйлап табучанлык сәләтен үстерү.

**Көтелгән нәтиҗә:** Проект тәмамлангач, укучылар: географик мәгълүматлар табу буенча проект эшендә катнаша алалар, тапкан мәгълүматны бәяли, тема буенча үз фикерләрен белдерә алалар.

**Эшемнең теоретик кыйммәте.**

Яңа стандартлар буенча, иң элек укучыда тирә-юньне тану буенча мотивацияне көчәйтергә, мәктәптә алган белем-күнекмәләрнең тормыштан аерым түгеллеген, ә нәкъ менә тормыш өчен әзерлек, аны өйрәнү, реаль тормышта куллану өчен кирәкле информация туплау дип аңлату.

**Эшемнең практик кыйммәте.** Укытучылар үз эшләрендә укучылар белән төрле темаларга презентацияләр төзегәндә һәм яклаганда куллана алалар.

**Проект методының асылы:** укучылар укытучы җитәкчелегендә эзлекле рәвештә проектлар эшлиләр, проект өстендә эшләгәндә өстәмә информация туплыйлар һәм һәр этапка рефлекция ясыйлар.

Укучы өчен проект нәрсә соң ул?

- Иҗади мөмкинлекләрен ачу;
- Төркемдә эшләү күнекмәләре булдыру;
- Үзе сайлаган кызыклы проблеманы (теманы) ачу өстендә эшләү;
- Үзенең эшен (хезмәтен) презентацияләү.

**Проект төрләре**

Проект эшләре төрләре берничә.

• **тикшеренү** (хезмәтнең актуальлеген нигезләү, тикшеренүнең максаты әйтү, бурычлар кую, аларны чишү юлларын күрсәтү);
• **иҗади** (кичә яки бәйрәм үткәрү өчен сценарий төзү, мәкалә язу һ.б.);
• **гамәли юнәлешле** (һәр укучының, төркемнең бөтен эшчәнлеген яхшы нәтиҗәләргә ирешү максатыннан чыгып планлаштыру);
• **мәгълүмати** (темага караган мәгълүматларны җыю, аларны катнашучыларга тәкъдим итү, фикер алышу, йомгаклау);
• **предметара** (берничә предметка нигезләнү).

Проект методы укытучы һәм укучыларның яхшы әзерлеген, сыйныфның һәм иҗади төркемнәрнең үзара килешеп эшләүләрен таләп итә. Проект турында сөйләшүдә катнашып, укытучы да тигез хокуклы фикердәшкә, ярдәмчегә әйләнә. Проектны гамәлгә ашыру барышында укучылар әйләнә-тирәдәгеләр белән уртак тел табып эшләргә,

фикерләрен дәлилләргә өйрәнә. Укучылар проектларны аерым яки иҗади төркемнәрдә эшли алалар.

**Проект өстендә эшчәнлек**

**Проект эшчәнлегенең унай яклары:**

-Укучы кызыксынып ирекле рәвештә сайлап алган тема өстендә эшли.

-Үзе сайлап алган эшне мавыгып, канәгатьләнү хисе белән башкара.

Проектлау, укучыларның мөстәкыйль эше булса да, педагог җитәкчелегеннән башка уңышлы була алмый. Шуңа күрә проект өстендә эшләү ике яклы, укытучы һәм укучы эшчәнлегеннән тора.

-кызыксындырган сорауны билгели, үзфикерен дәлилли;

-информацион чыганаклар туплый

-күзаллауны киңәйтүче темалар тәкъдим итә;

-проблемалы ситуацияләр тудыра;

-укучыларның сорауларына җавап

табу өчен тематик чикләрне билгели

**Аналитик этап**

***укучы***

***укытучы***

- информацияне системалаштыра;
- булачак «туачак»продуктны күзаллап тасвирлый;
- эш планын төзи

-күзәтә, алга этәрүче сорау һәм ситуацияләр булдыра;

- укучының хронологик тәртиптә эш итүе белән идарә итә;
- консультацияләр оештыра

**Практик этап**

***укучы***

***укытучы***

-мөстәкыйль рәвештә план буенча эшли;

- эшнең барышы белән уртаклаша

- мөстәкыйль эшләү мөмкинлекләрен булдыра;
- эш барышына карата анализ ясый;
- «проект дәфтәре» булдыру эшен оештыра

**Презентацион этап**

*укучы*

*укытучы*

-проектны презентацияләү формасын сайлый;

- эксперт ролен үти (башка укучыларга карата)

-бәхәс тудыручы сораулар әзерли;

- проектны кабул итәргә әзер булган аудитория әзерли

**Контроль этап**

*укучы*

*укытучы*

- бәяләү нормаларына туры китереп, проектка үзбәя бирә

«проект дәфтәре» булдыру эшен йомгаклый;

- алдагы үсеш юлларын ачыклый

Димәк, проект өстендә эш ниндидер конкрет, социаль әһәмиятле проблеманы чишүгә юнәлдерелгән булырга тиеш. Куелган проблеманы чишүдә эшләнәчәк эшне дөрес планлаштыруның әһәмияте зур. Һәр конкрет гамәл, аның нәтиҗәсе, срогы, җаваплы кешесе күрсәтелә. Шулай ук килеп чыгачак нәтиҗә-продукт һәм презентация формасы билгеләнергә тиеш. Һәр проектның төп шарты – укучыларның иҗади эшләве. Проектның характерлы үзенчәлеге булып укучыларның информация эзләве тора. Информация укучы тарафыннан өйрәнелә, эшкәртелә һәм тәкъдим ителә. Укучы информацияне турыдан туры бер җирдән икенче җиргә күчереп куярга гына тиеш түгел, үзенең фикерен дә белдерергә тиеш.

Проектның нәтиҗәсе булып укучыларның куелган проблеманы чишкәндә булдырган эш продукты тора.

Һәр проект үзенең тәмамлау этабында продуктны презентацияләү һәм яклаудан торырга тиеш. Димәк, проект эше түбәндәге тәртиптә бара:

Проблема – Планлаштыру – Информация эзләү – Продукт – Презентация.

Аның нигезе - тикшеренү эше.

**Проект формалаштырган күнекмәләр.**

Проект эшләү вакытында укучыларда түбәндәге күнекмәләр формалаша***:***

**1. Рефлексив күнекмәләр:**

- чишү өчен әле белемнәр җитеп бетмәгән мәсьәләне аңларга тырышу, акыл аша уздыру күнекмәсе;

- куелган проблеманы чишү өчен нәрсәне белергә, өйрәнергә кирәк, – дигән сорауга дөрес җавап таба белү күнекмәсе.

**2. Эзләнү- тикшеренү күнекмәләре**

- төрле өлкәдәге белемнәрне файдаланып, кирәкле эш ысулын уйлап табу күнекмәсе;
- информация кырынннан үзеңә кирәкле информацияне табу күнекмәсе;
- җитмәгән информацияне укытучыдан яисә белгечтән сорап алу күнекмәсе;
- проблеманы чишүнең берничә вариантын табу күнекмәсе;
- сәбәп- нәтиҗә бәйләнешен билгели белү күнекмәсе.

**3. Бәя бирү күнекмәләре.**

**4. Хезмәттәшлек күнекмәләре:**

- коллектив планлаштыру күнекмәсе;
- партнерга тәэсир итү күнекмәсе;
- уртак мәсьәләне чишкәндә ярдәмләшү күнекмәсе;
- партнерларның хаталарын күрә һәм төзәтә белү күнекмәсе;

**5. Коммуникатив күнекмәләр:**

- дискуссия алып бару күнекмәләре;
- үз фикереңне яклау күнекмәләре;
- компромисска бару күнекмәләре;
- сорау бирү, интервью алу күнекмәләре.

**6. Презентацияләү күнекмәләре:**

- монолог сөйләме күнекмәләре;
- чыгыш ясаганда үз- үзеңне тоту күнекмәләре;
- артистлык күнекмәләре;
- сөйләгәндә күрсәтмәлек куллана белү күнекмәләре;
- кисәк бирелгән сорауларга җавап бирү күнекмәләре.

”Туган ил,туган җир”электив курсы белем биреп кенә калмый, ә мөстәкыйль эшчәнлек күнекмәләрен булдырырга һәм һәр баланың шәхси мөмкинлекләрен ачарга, өлкән сыйныфларда укыячак профильне сайларга ярдәм итә.

Программаның эчтәлеге:

Россия үзенчәлекле – төньяк ил. Административ – территориаль төзелше һәм районнар бүленеше, кырый нокталары, табигый пояслары, елга системасы, геологик төзелеше, климаты, табигый ресурслары.  Туган җирем – Татарстан. Татарстанның дәүләт символлары, башкаласы, Казанның тарихи урыннары.  Арча – республиканың иң төньяк районы.  Географик урыны, халкы.  Арчаның гербы, гимны белән танышу. Районыбызның туган як музеена сәяхәт. Туган якның ачык китабы. Авылымның үткәне, һөнәре белән танышу. Носы, Ишнарат, Сәрдәбаш авыллары тарихы. Авыллар тарихы беләнтанышу, мәгълүмат җыюны дәвам итү.  “Җиде бабаңны беләсеңме?”. Шәҗәрәләр төзү. Туган ягыбызда тел үзенчәлекләре Район матбугаты тарихы.”Арча хәбәрләре”газетасы үсеше.

Туган авылымның топонимикасы. Носы , Ишнарат, Сәрдәбаш авылларының топографик картасын төзергә өйрәнү. Авылымның гидронимикасы. Чишмәләр турында мәгълүмат җыю. Халкыбызның күңел бизәкләре. Милли сәнгать үрнәкләре, чиккән сөлгеләр, мендәр япмалары, чулпылар, беләзек кебек бизәнү әйберләре белән танышу. Арча төбәгенең гореф-гадәтләре һәм әби-бабаларыбызның йолалары . Шушы яктан, шушы туфрактан без. Арча ягында туып үскән күренкле кешеләр турында белешмә, иҗат итүче райондашларыбыз авылдашларыбыз турында мәгълүмат бирү.

Календарь-тематик план

| № | Тема | Сәг | Үткәрү формасы | Дата | Өстәмә эш |
|---|---|---|---|---|---|
| 1-2 | Россия үзенчәлекле – төньяк ил. Административ – территориаль төзелше һәм районнар бүленеше, кырый нокталары, табигый пояслары, елга системасы, геологик төзелеше, климаты, табигый ресурслары | 2 | әңгәмә, лекция | сентябрь | Административ – территориаль төзелше һәм районнар бүленеше физик карта белән эшләү |
| 3-4 | Туган җирем – Татарстан. Татарстанның дәүләт символлары, башкаласы, Казанның тарихи урыннары. | 2 | әңгәмә, лекция | сентябрь | Презентация төзү |
| 5 | Арча – республиканың иң төньяк районы | 1 | әңгәмә, лекция | сентябрь | Район тарихына караган материаллар туплау. |
| 6 | Географик урыны, | 1 | әңгәмә, лекция | сентябрь | материаллар туплау. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | халкы | | | | |
| 7 | Арчаның гербы, гимны белән танышу | 1 | әңгәмә, лекция | октябрь | Иҗади бирем. Герб ясарга |
| 8-9 | Районыбызның туган як музеена сәяхәт | 2 | Сәяхәт-дәрес | октябрь | Иҗади эш “Туган ягымның киләчәге” |
| 10 | Туган якның ачык китабы. | 1 | әңгәмә, лекция | октябрь | Дару үләннәре  җыю |
| 11 | Авылымның үткәне, һөнәре белән танышу | 1 | Лекция, ,күзәтү әңгәмә | ноябрь | Фәнни эш-реферат язарга |
| 12 | Носы, Ишнарат, Сәрдәбаш авыллары тарихы. | 1 | Лекция, күзәтү әңгәмә | ноябрь | Фәнни эш- проект эше |
| 13 | Авыллар тарихы беләнтанышу, мәгълүмат җыюны дәвам итү. | 1 | әңгәмә, лекция | ноябрь | сочинение |
| 14-15 | “Җиде бабаңны беләсеңме?” | 2 | Эзләнү-тикшеренү эше | декабрь | Иҗади эш.Гаиләбезнең буыннан-буынга килгән традицияләре |
| 16-17 | Шәҗәрәләр төзү | 2 | Гамәли эш | декабрь | Шәҗәрәләр төзү |
| 18 | Туган ягыбызда тел үзенчәлекләре | 1 | Эзләнү-тикшеренү эше | декабрь | Туган ягыбызда тел үзенчәлекләрен өйрәнү |
| 19-20 | Район матбугаты тарихы.”Арча хәбәрләре”газетасы үсеше | 2 | Редакциягә сәяхәт | январь | Вакытлы матбугатка күзәтү,төбәгебездән чыккан кешеләрнең язмалары белән танышу |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 21 | Туган авылымның топонимикасы | 1 | әңгәмә, лекция | январь | Топонимикасын төзу |
| 22-23 | Носы , Ишнарат, Сәрдәбаш авылларының топографик картасын төзергә өйрәнү. | 2 | әңгәмә, лекция | январь | Топонимикасын төзу |
| 24 | Авылымның гидронимикасы | 1 | әңгәмә, лекция | февраль | Материаллар тупларга |
| 25 | Чишмәләр турында мәгълүмат җыю | 1 | Лекция,күзәтү | февраль | Арча турында язылган җырларны туплау. |
| 26 | Халкыбызның күңел бизәкләре | 1 | әңгәмә, лекция | февраль | Материаллар тупларга |
| 27-28 | Милли сәнгать үрнәкләре, чиккән сөлгеләр, мендәр япмалары, чулпылар, беләзек кебек бизәнү әйберләре белән танышу | 2 | әңгәмә, лекция | март | Материаллар тупларга |
| 29-30 | Арча төбәгенең гореф-гадәтләре һәм әби-бабаларыбызның йолалары | 2 | Эзләнү-тикшеренү эше | март | Иҗади эш.Гаиләбезнең буыннан-буынга килгән традицияләре |
| 31 | Шушы яктан, шушы туфрактан без | 1 | Очрашу,әңгәмә | апрель | Хезмәтләрен өйрәнү |
| 32-33 | Арча ягында туып үскән күренкле кешеләр турында белешмә, иҗат итүче | 2 | Әңгәмә, күзәтү | апрель | Проект әзерләү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | райондашларыбыз авылдашларыбыз турында мәгълүмат бирү. | | | | |
| 34 | Йомгаклау.Зачет-дәрес | 1 | Зачет-дәрес | май | |

**ЙОМГАКЛАУ**

Проект эшчәнлеге укытучы һәм укучыдан зур түземлек, сабырлык, күп вакыт сарыф итүне сорый.Тиешле нәтиҗәгә ирешү өчен, эш барышында өстәмә китаплардан, сүзлекләрдән, интернет аша күп мәгълүмат тупларга, иҗади фикер йөртергә кирәк.

Гомумән, проект методы - баланың интеллектын, иҗади сәләтен, логик фикерләвен үстерүдә, кызыксынучанлыгын арттыруда нәтиҗәле алымнарның берсе.

Алда язылганнардан чыгып, шуны әйтәсе килә, проект– ул күпкырлы, эффектив, перспективалы, иксез-чиксез эш.Проект – теләсә кайсы предметны өйрәнгәндә куллану мөмкинлеге булган метод. Аны дәрес вакытында һәм дәрестән тыш вакытта да кулланып була. Проект методы укучыларның үзләре куйган максатларын тормышка ашыруга корылган һәм шуңа күрә ул – *уникаль*. Ул күптөрле белем һәм күнекмәләр формалаштыра, шуңа ул *эффектив*.

Проект укучыларга шулкадәр кирәкле эш тәҗрибәсе бирә, шуңа күрә ул *алыштыргысыз*. Әйе, проектлар методын кулланып эшләү укытучыдан үз эшенә иҗади якын килүне таләп итә. Ул инде укытучы буларак кына түгел, режиссер нинди дә булса эшкә җитәкчелек итә, консультант яки башка рольгә кереп, укыту процессын оештыра.

Проект эшен куллану фән-техника зур тизлек белән үскән, радио-телевидениедә, интернетта чуар мәгълүмат ташкыны агылган һәм алардан күбесенчә тормышның тискәре яклары күрсәтелгән бер заманда югалып калмаслык, үз урынын табарлык нык ихтыяр көченә ия булган, белемле, әхлаклы һәм шуның өстенә бүгенге хезмәт базары шартларында көндәшлек сыйфатларына ия булырдай буынны тәрбияләүгә ярдәм итәр.

Кулланылган әдәбият


1. Атлас РТ
2. Резеда Валиева “ Күңелем гөлләре” шигырьләр җыентыгы
3. Р. Шәрәфиев “Уйлы күңел”
4. На берегу Ашит.
5. Татарстанның үсемлекләр һәм хайваннар җыентыгы
6. Ф. Гарипова. Татарская гидронимия. Казан -1998
7. Ф. Гарипова. Авыллар һәм калалар тарихыннан

Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча районы**

**«Носы төп гомуми белем бирү мәктәбе"**

**муниципаль бюджет белем бирү учреждениясе**

**Тема:**

"Сәрдәбаш авылының үткәне һәм бүгенгесе"

Эшләде: Уваева Диана Леонидовна

«Носы төп гомуми белем бирү мәктәбе"

8 класс укучысы

Җитәкче: Григорьева Лена Ильясовна

география укытучысы

Арча районы МБГБУ "Носы төп мәктәбе"

**Тикшеренеү эшебезнең актуаллеге:**

Минем эшемнең темасы: "Сәрдәбаш авылының үткәне һәм бүгенгесе" дип атала. Тема бик актуаль. Борынгы ата-бабалар: «Һәр кеше үзенең авылының, халкының тарихын белергә тиеш»,- тигән һәм үз балаларынан шушы кагыйдәне үтәне талап иткән. Шушы елларда үз тарихын өйрәнергә, тамырларын барларга теләүчеләр күп, ләкин үткән елларның тарихын, атамаларын өйрәнеп, язылып, барылмаган, бүгенге көндә эзләнүчеләр өчен авырлык тудыра. Атамалар- халыкның тарихын, тормыш-көнкүрешен, мәгънәсен чагылдырган тылсымлы көзге ул.

**Эзләнү эшемнең максаты:** авыл тарихы буенча фактлар табу һәм системалаштыру.
Иптәштәремдә тарихны өйрәнүгә кызыксынучанлык уяту.

**Эзләнү эшенең гипотезасы:**

1. Туган авылым Сәрдәбашның бай тарихы, матур киләчәге бар.

**Эзләнү эшенең методлары.**

-тарихны тикшерү.
-олылар белән очрашу.
-авылга бәйле әдәбият белән танышу.

**Тикшеренеү объекты**

Борынгыдан алып бүгенге көнгә кадәрге тарих..

Эзләнү методлары: Библиография беләнән эшләү. Эшне башкарганда крайны өйрәнү материаллары, архив документлары кулланылды.

- Әңгәмә. Материал туплаганда олылар, авыл кешеләре белән сөйләшү булды.

  Эзләнү. Материаллары (төрле мәгълүмәтләр, фотосүрәтләр, архив документлары) әти- әни, туганнарым, укытучым ярдәмендә җыелды һәм өйрәнелде.

**Эзләнүнең практик әһәмияте:**

**Җыелган** материаллар авыл тарихын өйрәнүгә, мәктәп музейеда файдалана ала.

План

1.Кереш өлеш

2. Максат һәм бурычлар

3.Төп өлеш

4. Йомгаклау.

5. Әдәбият

“Авылымның үткәне һәм бүгенгесе”

Кереш өлеш

Һәр кешенең йөрәгенә якын, җанына җиңеллек бирә торган урыны булырга тиеш. Минем өчен ул - туган авылым. Туган ягын, авылын яратмаган кешеләрне мин күз алдыма да китерә алмыйм. Яшьлекләрендә авылларын ташлап чит җирләргә киткән кешеләр дә, туган туфракларын сагынып, аның табигатенә сокланып, җырлар, шигырьләр язалар. Мин дә чын күңелемнән туган ягымны яратам, аның гүзәллегенә сокланам. Минем авылымны сөймәслек тә түгел шул. Ул миңа, барлык дөньяда шундый бер генә, бары тик бер генә! Җәй көннәрендә болын өстеннән талгын җил искәндә, болын өстенең дулкынлануыннан күзләреңне ала алмый торасың. Нинди генә чәчәкләр юк анда! Әйтерсең лә табигатьтә булган бар төсне шунда җыйганнар диярсең. Искиткеч гүзәллек! Әнә шул болын өстеннән әкрен генә иртәнге кояш күтәрелә. Әкияти манзара эчендәге авылым җәйләрен көннән көн матурлана, яшеллеккә күмелә.

Кеше үз гомерендә бер кайчан да туган җирен оныта алмый. Онытканн очракта да, яшь вакытында гына. Олыгайган көннәрендә ул барыбер, туган авылын, шәһәрен, гомуми әйткәндә туган җирен исенә төшерә һәм анда кайтырга омтыла башлый.

Мәсәлән туган авылында ел саен уза торган сабан туен гына алыйк. Сабантуй бәйрәме - татар халкының иң олы бәйрәмнәренең берсе. Ул - хезмәт һәм дуслык бәйрәме.

Әгәр дә һәрбер кеше дә үз туган җирләрендә яшәсә, минемчә, табигатьне саклау да башкачарак булыр иде. Чөнки туган җирен яраткан, аның белән горурланган кешенең кулы, аны пычыратуга, кыерсытуга сузылмас иде.

Үземә килгәндә, мин туган ягымны, туган җиремне, анда яшәүчеләрне, табигатень барысында яратам һәм шушы җирләремдә яшәргә калу исәбем!

Максат: Авылның үткәне һәм бүгенгесе белән танышу, танылган кешеләрен барлау.

Бурыч:

- топонимикасы
- гидронимикасы

- экологиясе

Төп өлеш.

Бала дөньяга килә, беренче тапкыр туган нигезендә үзенең тавышын яңгырата. Бу вакытта әле ул бернәрсә аңламаса да, әни назын тоеп, ата-баба нигезендә яши башлый. Кызарып чыккан кояшка карап, күзләрен ача, өй түрендәге кошлар сайравына елаудан туктый; яңгыр яуганда, йөзенә сәерсенү билгеләре чыгара. Анасы да баласының көләч, шат йөзен күреп, бишек җырын көйли, кытыршы куллары белән баласын назлый, чын күңелдән изге теләкләр тели.

Мин дә кечкенәдән ук әни назын тоеп, аның сүзләренә колак салып үстем. Әнкәемнең: «Туган-үскән җиреңә мәрхәмәтле бул, аны булдыра алганча ярат. Ата-баба нигезен онытма!» дигән сүзләре хәтеремә бик тирәнтен уелып калганнар. Ничек соң инде шундый гүзәл табигатьле, газиз туган ягыңны яратмаска мөмкин!?

Мин авылда тудым. Күпләрне сокландырган гүзәл табигате, бай мәдәнияте, эш сөючән халкы белән дан тоткан, Арча районының төньягында урнашкан авылларның берсе ул Сәрдәбаш. Табигатьнең иң ямьле җирендә тайгага кадәр тоташучы урманнарга сыенып утыра бу авыл. Аның тирә - ягындагы җиләкле болыннары, мул игенле басу кырлары, каз – үрдәк тулы инешләре, челтерәп аккан чишмәләре җанга рәхәтлек бирә, эшкә дәрт өсти. Сабый чагымда челтерәп аккан чишмә тавышын да, талларга кунып сайраган сандугач тавышын да ишеттем, йолдызлы күкне, тулган айны күреп сокландым. Безнең авылның табигате искиткеч матур. Мин, капка төбебезгә чыгу белән, үземне яшел хәтфә җәелгән җиргә баскан кебек хис итәм. Бәбкә үләннәре, вак ромашкалар, сары чәчәкләр үзләре үк мине бер сихри дөньяга алып кереп китәләр. Үзем яшел чирәмнән атлыйм, күзләрем тирә-якны күзәтә. Әнә якында гына бормаланып инеш ага. Җәй көннәрендә анда каз-үрдәк тавышлары ишетелә.

Инеш буенда өянкеләр үсә. Алар яз көне аксыл-яшел төскә керәләр, җәй башында яшел яфракларга төренеп, авылга ямь бирәләр, кичләрен кошларның матур тавышлары бөтен су буен җанландыра. Кичке сабантуй да инеш буенда уза. Яшьләрнең шат җырлары, уеннары белән су буе гөрләп тора. Авылдан ерак түгел урманнар бар. Урман яшеллеге, саф һавасы, җырчы кошлары белән үзенә гашыйк итә. Урманны бөтен кеше дә ярата торгандыр дип уйлыйм мин. Тукайның «Шүрәле» поэмасындагы түбәндәге юллар безнең авыл урманы турында язылган кебек:

Бик хозур! Рәт-рәт тора гаскәр кеби чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.

Җәй көне урман кешеләрне үзенә тарта. Ял көннәрендә төркем-төркем дә, ялгыз да кешеләр урманга агылалар. Җәй уртасында урман аланнарында чалгы тавышлары ишетелә. Ә көз кешеләрне үзенең сап-сары чикләвекләре белән кинәндерә.

Шушы гүзәллеккә кушылып, авылның борынгысын һәм бүгенгесен күзгә күренмәслек кыллар белән тоташтырып, гөслә моңы агыла. Әйе, гөслә моңы! Гөслә кылларыннанчыга ул сихри моң. Күңел түренә керүче көй аша борынгы бабаларыбыз авазы ишетелеп киткәндәй була. Күңелең авыл тарихын барлый башлый.

Урман белән капланган бу җирләргә моннан 200-250 еллар элек 2-3 гаилә килеп урнаша. Йорт җирләрен чишмәдәге тау башыга салып күмәк тормыш башлап җибәрәләр алар. Суы якын, урман янәшәдә – яшә дә яшә. Инеш буенда өянкеләр үсә. Алар яз көне аксыл-яшел төскә керәләр, җәй башында яшел яфракларга төренеп, авылга ямь бирәләр, кичләрен кошларның матур тавышлары бөтен су буен җанландыра. Тиздән бу тирәгә күчеп килүчеләр саны арта. Кешенең гомере башланып киткән кебек үк, инешнең дә башлангычы бар. Бу — чишмәләр. Чишмә, тау астыннан көмеш күзе белән җирне тишеп, бик зур кыенлыклар белән саркып чыга, бөдрә дулкыннар ясап, әкрен генә ага. Аның көмеш сыман тамчылары кояш нурлары астында энҗе бөртекләре кебек җемелдиләр.

Чишмәләр... Кемнең генә күңеленә илһам салмый да, кемгә генә канат куеп, хыялларын үстерми икән соң алар?! Шагыйрь Равил Фәйзуллин туган ягы, туган йорты турында күп яза. «Туган ягым» дигән шигырендә ул болай ди:

Минем дә бар үзем өчен
шундый як — Туган ягым:
Дога иңгән һәр төшеннән
чишмәләр чыга аның!

Сәрдә елгасы башланган җирдә урнашканга, авылны Сәрдәбаш дип атый башлыйлар. Тора – бара урман киселә төпләрдән арындырыла, чәчүлек җирләр әзерләнә, авыл зурая. Хәллерәк тормышлы берәүнең кибете, икенчесенең ярма яру җайланмасы, су көче белән эшләүче тегермәне була. Сәрдәбаш – керәшен авылы. Гомерләре ямансу.

Азатлык өчен халкымның
Кан-яшьләре тамган су, —

дигән юллар Иван Грозный яулары вакытында түгелгән яшьләр, каннар хакында сөйли.. Халык сөйләвенә караганда, Иван Грозный вакытында татар халкы христиан динен кабул итәргә мәҗбүр була. Шулай итеп, авылның төп халкын керәшен татарлары тәшкил итә.

Туган ягымның гүзәл кешеләре, гыйбрәтле тарихы да бар. Сугышка кадәр авылда агачтан өйберләр ясаучы оста Федоров Николай Федорович яши. Ул чиләкләр, уфалла арбалары белән тәэмин итеп тора. Авыл хуҗалыгында җитен, киндер үстерәләр. Халык чабата ясап, капчык тегеп сатып, чыпта сугып көн күрә.

1931 нче елда Зиннур бабайдан тартып алынган йортның өске катында клуб ачыла, ә аскы өлешендә пекарня эшли башлый. Шул ук елны Тимербай йорты кибет ителә. 1939 нчы елның 10 нчы октябрендә беренче мәктәп ачыла. Ул елларда авылда балалар бакчасы

да эшли.   Сугыш елларында Эстониядән эвакуацияләнгән 2 балалы ана Валентина хуҗалык өендә медицина хезмәте күрсәтелә башлый. Соңрак медпункт ачыла.Сугыш елларында  итекчеләр Дмитрий,Роман бабайлар халыкны, тирә – яктан килүчеләрне җылы киез итекләр белән тәэмин итеп торалар. Аулак өйләрдә кызлар чигү чигә, челтәр бәйли. Шунда ук алар, гөслә уйнап, күңелләрен күтәрә, сагышларын баса, сугыш хәсрәтен онытып тора.

1933 нче елда Калинин исемендәге күмәк хуҗалык оеша. Яшьләр сыер, сарык, дуңгыз фермаларында тырышып эшли. Соңрак  куян, тавык фермалары да ачыла. Яшелчә бакчасында кыяр, суган, кәбестә үстереп фронта озатыла. Алма бакчасында, урматалыкта эш гөрли. Авыл халкы авыр хезмәтне ял белән чиратлаштырып яши белә: сугышка кадәр 33 гөсләче берләштергән ансамбль оеша. Ул  ансамбль Казан, хәтта Мәскәү сәхнәләрендә чыгыш ясый. Ансамбль кызларын гөсләләр белән бертуган осталар Архипов Роман һәм Сарафионовлар тәэмин итеп торалар.

1956 нчы елда Кызыл –Юл районы, Калинин колхозының Сәрдәбаш авылына беренче трактор кайтарыла.

1957 нче елда Сәрдәбаш “Северный” совхозы составына кушыла.

Авыл хуҗалыгында күп еллар намуслы хезмәте өчен Николаев Павел хөкүмәт тарафыннан Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм Ленин ордены белән  бәләкләнә.  1990 – 2001 елларда Сәрдәбаш авылы “Носы совхозы состафында яшәде.  2001 нче елның октябрендә “Носы” совхозы яңадан “Северный” күмәк хуҗалыгына кушыла.2001 нче елның 6 нчы мартында яңа мәктәп ачылды. 2007 елда яңа медпункт эшли башлады. Хәзергә көндә авылның 82 хуҗалыгында 296 кеше яши. Зур киңлекләр биләүче басуларда күп төрдәге авыл – хуҗалагы өчен файдалы булган культуралы үсемлекләр үстерәләр. Безнең күмәк хуҗалыгы бигрәк тә бәрәңге үстерү, ашлык җыеп алу буенча алдынгы урыннар алып бара. Шулай ук кукуруз, бодай, солы, борчакны күпләп үстерәләр. Бер яктан гүзәл матурлык балкып торса, икенче яктан тискәре яклары да күренә. Моны кешеләр тарафыннан килеп чыккан проблемалар дип карасак та ялгыш булмас иде. Һәм без шушы проблема өстендә хзлебездән килгәнчә эшлибез, туган ягыбызның кайбер үзенчәлекле якларын җентекләп өйрәнәбез. Беренче чиратта ул безнең күз карашына матур табигать шартлары буларак килеп баса. Моңа  тагын иксез – чиксез булган басу - кырларны, экологик яктан чиста булган барлык торак  -  пунктларны чиратлаштырып карап узарга мөмкин.

Авылымда экологик проблемалар чиктән тыш артып китте. Бигрәк тә түбәндәге проблемалар күп күзәтелә:

- суның пычрануы, агулы матдәләр таралу;
- ландшафтларның бозылуы;

- урманнарның юкка чыгуы һәм аның территориясенең сөрүлек җирләренә әверелүе;
- кышын кар капламы юка булып, дымның аз булуы;
- җәен кояшның эссе җылытуы һәм үсемлекләрнең коруы, бу уңышның аз булуына китерә;
- ашламалар белән җирне, туфракны зарарлау;
- чүплекләрнең күбәюе һәм су белән агып төшеп елгаларны зарарлавы;
- үсемлек тәрләренең юкка чыгуы, урмандагы җәнлекләрне аулау, балыкларны тотып төрен киметү, кызыл китапның калынаюы.

Йомгаклау. Табигатьнең матурлыгы, байлыгы кем кулында?

-Кешенең сәламәтлеге, бәхете, тыныч, мул яшәве нәрсәгә бәйле?

-Адәм баласы тумышыннан соңгы сулышына кадәр табигать белән аерылгысыз бәйләнештә.Табигать-анабыз безне туендыра, яшәргә көч бирә, киендерә, җылыта, эчәр суын бирә. Шуңа күрә аны сакларга кирәк.

-Ә табигатьне саклау дигәнне сез ничек аңлыйсыз?

-Табигатьне саклау – ул үзебезне, киләчәгебезне саклау, өебезне саклау дигән сүз ул. Без дә сезнең белән бу эштә үзебезнең өлешебезне кертә алабыз.

Һәр елның 5 июнендә кешелек җәмгыяте Бөтендөнья мохитне саклау көнен билгеләп үтә. Без дә бу көнне искә алып, әйләнә-тирәбезгә игътибар белән карап, авыл урамнарын, аның тирә-юнен, су чыганакларын һ.б. тәртипкә китерергә вакытны кызганмыйк.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Татарстан Республикасы: кыскача географик белешмәлек.- Казань, 2013.
2. Кызыл китап.
3. Мәгариф журналлары.